РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» февраля 2024 ел г. Альметьевск № 780

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләренең ireklk ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ирекле ярдәм итү (волонтерлык) оешмалары белән үзара эшчәнлек тәртибен раслау турында» 2018 елның 5 сентябрендәге 1319 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 27 ноябрендәге 558-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, хокукый мониторинг тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләренең ирекле ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручылар, ирекле ярдәм итү (волонтерлык) оешмалары белән үзара эшчәнлек тәртибен раслау турында» 2018 елның 5 сентябрендәге 1319 номерлы карарына (район Башкарма комитетының 2019 елның 11 декабрендәге 2140 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Җирле үзидарә органнары «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының башка норматив хокукый актлары, муниципаль норматив хокукый актларда каралган формаларда ирекле ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм күрсәтә.

Җирле үзидарә органнары тарафыннан ирекле ярдәм (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм түбәндәге рәвешләрдә күрсәтелергә мөмкин:

1) финанс ярдәме, шул исәптән грантлар һәм субсидияләр бирү;
2) оештыру ярдәме;
3) мәгълүмати ярдәм;

заказ № 1-851

4) консультация ярдәме;

5) мөлкәти ярдәм, шул исәптән биналарны түләүсез файдалануга бирү;

6) методик ярдәм.

Ирекле (волонтерлык) эшчәнлегендә катнашучыларга ярдәм итү чаралары исемлеге, 1995 елның 11 августындагы «Хәйрия эшчәнлеге һәм иреклелек (волонтерлык) турында» 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.4 статьясындагы 2 пунктчасында каралган формаларны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының башкарма комитеты - җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.

Күрсәтелгән ярдәм чаралары турында мәгълүмат «Хәйриячелек эшчәнлеге һәм иреклелек (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.5 статьясындагы 2 пунктында каралган тәртип нигезендә ирекле ярдәмчелекне (волонтерлыкны) үстерү өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштырыла.

Коммерция оешмалары булган ирекле ярдәм (волонтерлык) эшчәнлеген оештыручыларга финанс һәм мөлкәти ярдәм күрсәтү рөхсәт ителми.»

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С. В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов